**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы**
**Яңа Элмәле авыл җирлеге гражданнары җыены**
**КАРАРЫ**

# Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлеге составына керүче Иске Элмәле, Яңа Элмәле торак пунктларында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**№2** **15.10.2021 ел**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлеге составына керүче Иске Элмәле һәм Яңа Элмәле торак пунктларында гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

1. 2022 елда Яңа Элмәле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 600 сум күләмендә үзара салым кертергә көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, 1 төркем инвалидлардан тыш.

2.Алынган чараларны җибәрергә:

- җәйге һәм кышкы чорда юлларны төзекләндерүгә, карап тотуга, хезмәт күрсәтүгә чыгымнар (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдлау, кышкы чорда урамнарны кардан чистартуга, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр, элмә һәм тагылма җиһазлар сатып алуга, тракторчыга хезмәт күрсәтүгә түләү) Яңа Элмәле һәм Иске Элмәле торак пунктларында;
- Яңа Элмәле һәм Иске Элмәле авылларында урамнарны яктырту, монтажлау, ремонтлау, карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- юл билгеләре сатып алу:
- «Авыл территорияләренең заманча йөзе» республика программасында катнашу өчен проект-смета документларын, дәүләт экспертизасын әзерләү һәм түләү:
- Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Иске Элмәле авылында Сөлчә елгасы аша җәяүлеләр күперен капиталь ремонтлау, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) үтәү өчен кирәкле материаллар сатып алу.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**
**Яңа Элмәле авыл җирлеге башлыгы** **Мельников В.П.**